ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 647-148/тэ-2025

Казан шәһәренең социаль әһәмиятле кулланучыларның аерым категорияләре (төркемнәре) өчен җылылык энергиясен куллану булмаганда резерв җылылык егәрлеген саклап калу буенча «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр өчен 2026 елга түләү билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2025 ел, №34-ПР идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Казан шәһәренең социаль әһәмиятле кулланучыларның аерым категорияләре (төркемнәре) өчен җылылык энергиясен куллану булмаганда резерв җылылык егәрлеген саклап калу буенча «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр өчен календарь буенча бүленгән түләүне билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 647-148/тэ-2025
карарына кушымта

2026 елга Казан шәһәренең социаль әһәмиятле кулланучыларның аерым категорияләре (төркемнәре) өчен җылылык энергиясен куллану булмаганда резерв җылылык егәрлеген саклап калу буенча «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр өчен календарь буенча бүленгән түләү

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Резерв җылылык егәрлеген саклау хезмәтләре өчен түләү, айга сум/Гкал/сәг. |
|---|---|---|---|
| | Казан шәһәре | | |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 168 577,38 |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 267 702,85 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге